# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**16 ноябрь 2021 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 16 нояберендә үткәрелгән гражданнар җыенының «2022 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Күтәмәле авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);
- җәйге чорда территорияне чабу, урып-җыю (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- «Беларус-82,1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
- Күтәмәле авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Күтәмәле авылы Гагарин урамындагы күперне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
- бәйрәмнәр үткәрү өчен , бүләкләр алу (Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне);
- некрологларны һәм юбилярларның котлавын район газетасында бастырып чыгару

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 201 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 160 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 160 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл жирлегенең Күтәмәле авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Күтәмәле авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);
- җәйге чорда территорияне чабу, урып-җыю (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- «Беларус-82,1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
- Күтәмәле авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Күтәмәле авылы Гагарин урамындагы күперне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
- бәйрәмнәр үткәрү өчен , бүләкләр алу (Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне);
- некрологларны һәм юбилярларның котлавын район газетасында бастырып чыгару

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Имән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Гараев Р. Ф. Гараев